КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 октябрь г.Казань № 845

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 июнь, 393 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 955 нче; 2015 ел, 3 октябрь, 739 нчы; 2017 ел, 27 октябрь, 813 нче; 2017 ел, 22 декабрь, 1021 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1269 нчы; 2019 ел, 1 ноябрь, 994 нче; 2020 ел, 15 октябрь, 930 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1348 нче; 2022 ел, 9 март, 211 нче; 2022 ел, 19 сентябрь, 1017 нче; 2024 ел, 13 май, 321 нче; 2024 ел, 7 октябрь, 863 нче; 2024 ел, 16 декабрь, 1149 нчы; 2025 ел, 17 апрель, 242 нче; 2025 ел, 26 сентябр, 757 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрне башкарган өчен;»;

15 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрне башкарган өчен хезмәткәрләргә эшләрне фактта башкару вакыты өчен билгеләнә торган түләүләр:»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус булган эшләрне башкарган өчен хезмәткәрләргә даими нигездә билгеләнә торган түләүләр:

1) хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләр өчен – окладның 12 проценты.

Башкарыла торган эшне хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләргә кертеп карау хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру нәтиҗәләре нигезендә Учреждение җитәкчесе (башлыгы) боерыгы белән гамәлгә ашырыла;

2) Россия Федерациясенең законнар һәм башка норматив хокукый актлары белән каралган компенсация характерындагы башка түләүләр билгеләнергә мөмкин.»;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин